Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара
авыл җирлеге Советы
КАРАР

«19» января, 2024 ел № 1

Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Зур Кукмара торак пунктында «Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Зур Кукмара авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча халык җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 24 ноябрендәге 1 номерлы халык җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча халык җыены үткәрүне билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә Зур Кукмара авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРДЕ:

1. 2024 елның 30 гыйнваренә 16 сәгать 00 минутка «Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Зур Кукмара авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча халык җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 24 ноябрендәге 1 номерлы Зур Кукмара авылы халык җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча халык җыены үткәрүне билгеләргә. Җыенны Зур кукмара авылы Мәктәп урамы 5 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы зданиясендә үткәрергә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Кукмара муниципаль районының Зур Кукмара торак пунктында «Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Зур Кукмара авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча халык җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 24 ноябрендәге 1 номерлы халык җыены карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә ризамы:

«РИЗА» «КАРШЫ»

1 пунктның икенче абзацында “1000 сум" сүзен “1500 сум” сүзләре белән алыштырырга.

3.Әлеге карарны авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Җирлек башлыгы Р.Р. Хәнәфиев